# КЕРЕШ

Күңелне әсир иткән чын сәнгать әсәрен укып чыккач, бер мәлгә авторны күзалларга тырышасың. Нинди уй-фикерләр дулкынында, ни рәвешле язган ул әсәрләрен, кулына каләм алырга аны нәрсә этәргән? Ахыр чиктә шагыйрь яки язучы шундый әдәби камиллеккә һәм осталыкка ничек ирешкән? Иҗат эшчәнлеге гаять серле булганга, танып белүне дә үз итмәгәнгә, мондый сораулар еш кына җавапсыз кала. Әмма шунысы мәгълүм: осталык һәрвакытта да осталыкның үзеннән башланмый. Язучы аңа акрынлап, тора-бара ирешә. Шуңа күрә дә теге яки бу әдипнең иҗатын өйрәнгәндә, аның талантын дөрес бәяләү өчен, әдәби осталык мәсьәләсенә игътибар итү аеруча зарур.

Талант, әдәби осталык... Бу төшенчәләр әдәбият белемендә бер тирәдәрәк йөри, уртак мәгънә төсмерләренә ия. Әдәбият белгече Б. Мейлах фикеренчә, аерым алганда, талант ул — иҗади мөмкинлек[1]. Чыннан да, ул һәрвакыт уңышлы әсәр язуның гарантиясе була алмый. Хәтер, тирә-юньгә үткен караш, иҗади сизгерлек, күзаллау, ассоциативлыкның дәрәҗәсе белән аерылып торган тумыштан бирелгән психологик категория — талантның үсеше башка объектив һәм субъектив шартларга да бәйле. Мәсәлән, «иҗади климат», язучының аң-белеме, дөньяга мөнәсәбәте һәм, иң мөһиме — алда әйтелгәнчә, аның әдәби осталыгы.

Теге яки бу әдипнең осталыгын аның әсәрләрендәге тел-сурәтләү чаралары кулланышын тикшерү, композиция-сюжет корылышын анализлау аша өйрәнү актив һәм нәтиҗәле ысул булып саналса да, ул бу мәсьәләне һәрьяклап чишеп бетерми. Чөнки әлеге очракта без әзер текст — әдипнең төгәлләнгән әсәрләре белән эш итәбез. Ә язучының әдәби осталыгы турыдан-туры эш барышында чагыла, шуңа күрә ул, процесс буларак, үсештә, хәрәкәттә каралырга тиеш. Әгәр дә әдәби осталык турында тәмамланган текстларга карап кына фикер йөртсәк, без бары яхшы иҗат ителгән, уңышлы килеп чыккан образ, сурәтләрне генә ачыклыйбыз, ә әсәрне язуга салынган тырышлык, тәмамланган текстка кадәрге үсеш-үзгәрешләр күренми.

Аннан соң бу юнәлештәге эзләнүләрдә, хәтта фәнни хезмәтләрдә дә ясалмалырак бер тенденция күзәтелә. Авторлар әдәбият теориясендә беркетелгән төшенчә-чараларга билгеле бер калыпта билгеләмә бирәләр дә шагыйрь яки язучы

[1] *Мейлах Б.* Талант писателя и процессы творчества. — Л. : Сов. писатель, 1969. — С. 8.

иҗатыннан шуңа мисаллар китерәләр, текст тукымасындагы вазифасын билгелиләр. Җыеп әйткәндә, бу юлга таянып эш иткәндә, әдипнең күбрәк нәрсә иҗат итүе генә игътибар үзәгенә алына, ә аның ничек язуы читтәрәк кала.

Әдәби осталыкны, әдипнең иҗатын тагын да тулырак, тирәнрәк аңларга аның иҗат лабораториясен өйрәнү ярдәм итә. Бу — бик катлаулы, киңкырлы күренеш. Иҗат лабораториясе төшенчәсенең эчтәлеге үз эченә күптөрле элементларны сыйдыра: каләм иясенең табигый таланты, әдәби хезмәтнең шартлары, психологик үзенчәлекләре, индивидуальлеге, дөньяга карашлары, традицияләргә мөнәсәбәте — болар гомуми һәм киңрәк мәгънәгә ия. Әдип аңында тормыш материалының әдәби эшкәртелүе, уйниятнең тууыннан әсәрнең тәмамланган, соңгы вариантына кадәр үсеш-үзгәрешләр, андагы уңышлар, «иҗат газабы» бу мәсьәләне конкретрак чагылдыра. Язучының иҗат лабораториясе дигәндә, без иң беренче чиратта әдәби эшчәнлекнең нәтиҗәсенә түгел, ә менә аңа ирешү барышына игътибар итәргә тиешбез.

Татар әдәбият белемендә язучыларның, шул исәптән шагыйрьләрнең, иҗат лабораториясен, әсәрләренең язылу барышын монографик планда өйрәнүгә багышланган хезмәтләр бик аз. Иҗат лабораториясе мәсьәләсенең бик четерекле нәрсә булуын, язучы күп вакыт үзенең ничек эшләгәнен дә белеп бетермәвен сүз осталары үзләре дә еш искәртәләр. Бүгенге әдәбият фәне югарылыгыннан күренекле каләм әһелләренең иҗат лабораториясен, әдәби осталыгын өйрәнүгә ихтыяҗ зур булып кала бирә.

Шигърият мәйданына Тукай мәктәбе аша килеп, узган гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының әйдәп баручы әдибе булып танылган Сибгат Хәким иҗаты — чын мәгънәсендә әдәби осталык үрнәге. С. Хәким — индивидуаль стиле, табигый таланты, тирән лиризмы белән мәгънәвиэстетик яктан бай иҗади мирас тудырган һәм татар әдәбияты тарихында кабатланмас үз урынын булдырган күренекле шагыйрь. Аның лирикасы турында Ә. Фәйзи төгәл һәм кыска рәвештә: «С. Хәким шигырьләренең җанлылыгы, тормышчанлыгы аның олы эчкерсезлеге нәтиҗәсе булса, әсәрләренең гадилеге һәм халыкчанлыгы — тел өстендә өзлексез тырыш хезмәт җимешләре»[1], — ди.

С. Хәкимнең поэтик теле, үзенчәлекле сурәтләү чараларына бай шигъри текстлары һәрвакыт игътибарга лаек.

---

[1] *Фәйзи Ә.* Әдипнең эрудициясе. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1973. — 200 б.

Шагыйрьнең стиле, таланты стилистик фигураларны әсәрнең интонацион-фикри агышы белән яраштырып, җыйнак итеп сурәтләүдә ачык чагыла.

Иҗат лабораториясенә мөрәҗәгать итү С. Хәкимнең әдәби осталыгын процесс рәвешендә өйрәнергә, лирикасын тулырак күзалларга ярдәм итә. Иҗат манерасын тикшереп, шагыйрьнең дөньяга карашларын, мөнәсәбәтен, уйкичерешләрен, шуларны әсәрләрендә ничек чагылдыруын күрергә, гомумән, чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтләүнең катлаулы процесс булуын аңларга, әсәрләренең эстетик кыйммәтен ачарга мөмкин. Шәхси архив материалларына таянып, уй-ниятләренең барлыкка килүен, текстларының язылу тарихын белү, кулъязма вариантлардагы үсеш-үзгәрешләрне күзәтү әсәрләренең эчтәлегенә тирәнрәк үтеп керергә, аны яхшырак кабул итәргә булыша. Шагыйрьнең иҗат лабораториясен тикшерү шулай ук аның шәхси сыйфатлары турындагы мәгълүматларны күзаллауны киңәйтә. Аннан соң талантлы әдипнең әсәр иҗат итү тәҗрибәсе, язучылык эшчәнлегендәге гомуми яклар белән индивидуаль үзенчәлекләренең чагылышы, мөнәсәбәте – яшь буын каләм ияләре, тәнкыйтьчеләре өчен гаять кыйммәтле иҗат мәктәбе ул.

Бу өлкәнең киңкырлы һәм серле икәнен исәпкә алганда, әлеге хезмәтне дә шушы юнәлештәге эзләнүләрнең башлангычы, бер тармагы итеп карарга кирәк. Биредә урын алган фикер, күзәтүләр иҗат лабораториясен һәм С. Хәкимнең әдәби эшчәнлеген өйрәнүдә туплаган эзләнүләрне тулыландырып торачак.

## «Яшәсен тик кулда каләм, кәгазь...»

*(С. Хәкимнең шәхси архивына күзәтү)*

Һәр язучының иҗат эшчәнлегендә берничә катламны аерып чыгарырга мөмкин. Барлык укучыларга да мәгълүм һәм һәркем таныша ала торган катлам — аның басылып чыккан әсәрләре. Әдәби әсәрләр исә әдипнең аңында ярала башлый. Язучының үзе генә белгән күңел кичерешләре, күтелмәгән ачышлары, ягъни башкалар хөкеменә бирелми торган эчке халәте, фикер-хис туу барышы, икенче катламны тәшкил итә. Болардан тыш, әдипнең шулай ук иҗат лабораториясе белән турыдан-туры бәйле уйлануларын, күзәтү-эзләнүләрен туплаган куен дәфтәрләре, көндәлекләре һәм, әлбәттә инде, әсәрләренең кәгазьдәге үсеш-үзгәреш өлешен чагылдырган кульязмалары тагын аерым бер катламны барлыкка китерәләр. Соңгысы, бербөтен буларак, шәхси архивларның нигезен хасил итә. Билгеле булганча, архивлар мәдәни хәзинәләрне, үткәнгә караган документаль мәгълүматларны саклый. Шул ук вакытта алар язучы иҗатының, тормышының төгәл фактларын гына күрсәтеп калмый, ә ул яшәгән дәвернең рухын да чагылдыра.

Иҗат итү манерасыннан, кульязма әдәбиятка субъектив мөнәсәбәттән чыгып, язучыларның шәхси архив материаллары күләм һәм жанр ягыннан төрле булучан. Мәсәлән, бер тип язучылар иҗат эшчәнлегендә көндәлекләр алып бару, куен дәфтәрләренә фикер, тормыш картиналарын теркәп баруны мөһим дип санасалар, икенчеләре моның кирәксез нәрсә булуын белдерәләр. Шулай ук шәхси архивларның күләме объектив сәбәпләр, аерым алганда, янгын, югалу нәтиҗәсендә дә кимергә мөмкин. Әмма шунысы ачык: әдәбият фәне өчен шәхси архивлар — бик күп мәгълүмат бирә торган гаҗәеп кызыклы, мөһим чыганак.

Чыннан да, күренекле татар шагыйре С. Хәкимнең иҗат итү үзенчәлекләрен, стиль алымнарын, идея-эстетик карашларын, аерым әсәрләренең туу тарихын өйрәнүдә шәхси архив материаллары нык ярдәм итә. Бу чыганаклар тулысынча «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее фондында саклана. Архивны бирегә 1993 елда шагыйрьнең хатыны Мөршидә Вилданова-Хәкимова тапшырган.

«С. Хәкимнең музейларга карашы үтә җитди һәм җаваплы, ә музей хезмәткәрләренә карата бик җылы һәм ихлас иде. Ул күп мәртәбәләр әдәби кичәләрдә чыгышлар ясады, шигырьләрен укыды, музейның гыйльми совет әгъзасы буларак, һәрвакытта да үзенең төпле фикерен әйтә килде», — дип искә ала музей хезмәткәре И. Минһаҗева.

Архивның күләме чагыштырмача бик зур — 4 492 саклау берәмлегеннән гыйбарәт. Аларны, гомуми характеристика биреп, түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

| № | **Материал-чыганакларның эчтәлеге** | **Материал-чыганаклар кайсы елларга карый** | **Саклау берәмлекләре** |
|---|---|---|---|
| 1 | Блокнотлар | 1949–1986 | 13407/1–153 |
| 2 | Шигырьләр | 1938–1985 | 13407/154–180 |
| 3 | Поэмалар | 1948–1983 | 13407/181–193 |
| 4 | Тәрҗемәләр | 1940–1985 | 13407/194–238 |
| 5 | Публицистика | 1948–1980 | 13407/239–271 |
| 6 | Документлар, истәлекләр | 1939–1983 | 13407/272–346 |
| 7 | Фоторәсемнәр | 1944–1986 | 13407/347–481 |
| 8 | Хатлар (үз кулы белән язылган) | 1943–1985 | 13407/482–518 |
| 9 | Язучылардан килгән хатлар | 1940–1986, 1987 | 13407/519–1058 |
| 10 | Тәрҗемәчеләрдән килгән хатлар | 1950–1986 | 13407/1059–1465 |
| 11 | Башка республика язучыларыннан килгән хатлар | 1950–1984 | 13407/1466–1554 |
| 12 | Башкортстан язучыларыннан килгән хатлар | 1940–1985 | 13407/1555–1631 |